ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 июль 2020 ел № 3470

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең һава киңлегеннән файдалануның федераль кагыйдәләренең 49 пункты, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2012 елның 16 гыйнварындагы 6 номерлы приказы белән расланган «Россия Федерациясенең һава киңлегеннән файдалануны планлаштыруны оештыру» федераль авиация кагыйдәләренең 40.5 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 номерлы, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 номерлы, 2017 елның 8 февралендәге 588 номерлы, 2018 елның 18 июлендәге 4000 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 4226 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 номерлы, 2019 елның 5 мартындагы 1144 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 2663 номерлы, 2019 елның 8 ноябрендәге 5755 номерлы, 2020 елның 7 февралендәге 545 номерлы, 2020 елның 28 февралендәге 980 номерлы, 2020 елның 8 маендагы 2152 номерлы, 2020 елның 22 маендагы 2407 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, 75 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«75. Яр Чаллы шәһәре өстендә авиация эшләре, парашюттан сикерү, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз һава судноларының очышлары (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава судноларының очышларыннан тыш), бәйләп куела торган аэростатларны күтәрү, шулай ук алар хакында белешмәләр аэронавигация мәгълүматлары документларында күрсәтелмәгән Яр Чаллы шәһәре чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга төшү (очып китү) өчен рөхсәт бирү.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов